**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 июль № 533

г. Казань

«А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен аңарга «Казан җир өсте һәм җир асты электр транспорты техникумы» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен кушу юлы белән үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләрне һәм урта звено белгечләрен әзерләү сыйфатын күтәрү, кадрларны әзерләү күләмнәрен арттыру һәм хезмәт ресурсларыннан нәтиҗәлерәк файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы) аңарга «Казан җир өсте һәм җир асты электр транспорты техникумы» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – Казан җир өсте һәм җир асты электр транспорты техникумы) кушу юлы белән, А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы эшчәнлегенең төп максатларын саклап, үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда тиешле финанс елына һәм план чорына әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумын гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениене үзгәртеп оештыруга бәйле, законнар белән күздә тотылган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәп, Казан җир өсте һәм җир асты электр транспорты техникумында укучыларны ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, укыту шартларын һәм программаларын саклап, А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумына күчерүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

30 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләрне кертергә:

А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы уставына;

А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Казан җир өсте һәм җир асты электр транспорты техникумының оператив идарә хокукында А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумына бирелергә тиешле мөлкәте исемлеген, шулай ук Казан җир өсте һәм җир асты электр транспорты техникумына оператив идарә хокукында беркетелгән күчемсез мөлкәттән алга таба файдалану турында тәкъдимнәр кертергә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, А.П.Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы уставын раслаганнан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына аны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\533.doc